**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

26.12.2022 **Чирмешән авылы** № 473

«Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 511 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 24 декабрендәге 511 номерлы «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»ның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын бәян итәргә: «Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автоматик рәвештә, орган (оешма) тарафыннан билгеләнә торган таләпләр нигезендә гарызнамәче тарафыннан электрон рәвештәге соратуның һәр кырын тутыру процессында гамәлгә ашырыла. Бердәм портал электрон формадагы гарызнамәнең дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, гарызнамәчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны электрон рәвештә төзәтү тәртибе турында хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесенең беренче урынбасары И.Н.Шәйдуллин